ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында махсус хәрби операция ветераннарына һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.Ә. Зарипованың Татарстан Республикасында махсус хәрби операция ветераннарына ярдәм чаралары турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында махсус хәрби операция ветераннарына ярдәм чаралары турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы территориясендә ярдәм итү мәсьәләләре буенча региональ ведомствоара комиссия эшчәнлегенең, шул исәптән махсус хәрби операция ветераннарына ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен хәл итүдә ведомствоара хезмәттәшлекне һәм «Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасында күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында» 2025 елның 12 мартындагы 48-VII ДСП номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарында бәян ителгән тәкъдимнәрне үтәүне оештыруда, нәтиҗәлелеген билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына сайлау округлары территорияләрендә махсус хәрби операция ветераннарына һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Махсус хәрби операция ветераннары мәнфәгатьләрендә бурычларны комплекслы хәл кылуны тәэмин итү максатларында республика башкарма хакимият органнарының җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеген көчәйтергә.

4.2. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны, шул исәптән махсус хәрби операция ветераннарын, эшкә алу өчен эш урыннарын резервлау турындагы Татарстан Республикасы законнарын үтәмәгән өчен эш бирүчеләргә административ җаваплылык билгеләүнең максатка ярашлы булуы хакындагы мәсьәләне карарга һәм, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертергә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Махсус хәрби операция ветераннарына медицина ярдәме, шул исәптән югары технологияле, күрсәтү буенча дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеген координацияләүне дәвам итәргә.

5.2. Махсус хәрби операция ветераннарына тирәнтен диспансеризация, чираттан тыш медицина тикшеренүләре, реабилитация үткәрүне тулы күләмдә тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына демобилизацияләнгән махсус хәрби операциядә катнашучыларны аларның сәламәтлеге торышына карап эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшен активлаштыруны тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (региональ эш бирүчеләр берләшмәсе), Татарстан Республикасының кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе белән берлектә Татарстан Республикасында эш бирүчеләргә хезмәт һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга сала торган законнарның үзгәрүе турында, инвалид булган махсус хәрби операция ветераннары өчен эш урыннарын саклап калганда яисә булдырганда эш бирүчеләргә ярдәм итүнең региональ чаралары хакында, махсус хәрби операция ветераннары өчен эшкуарлыкка өйрәтү программаларын гамәлгә ашыру турында оператив хәбәр бирүне гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына махсус хәрби операциядә катнашучылар балаларының ялын һәм савыгуын оештыру мөмкинлеге турында гражданнарга хәбәр итү эшен көчәйтүне тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына инвалид булган махсус хәрби операция ветераннарын адаптив физик культура, адаптив спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, инвалидларга һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларга яраклаштырылган спорт төрләре буенча ярышларда катнашуга әзерләү эшен көчәйтүне тәкъдим итәргә.

10. «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәм фондының Татарстан Республикасы буенча филиалына махсус хәрби операция ветераннары һәм аларның гаилә әгъзалары хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча республика башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мәгълүмат алмашуын, шул исәптән «Ватанны саклаучылар» дәүләт мәгълүмат системасын кертү кысаларында, көчәйтүне тәкъдим итәргә.

11. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

11.1. «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга дәүләт ярдәм фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы белән бергә инвалид булган махсус хәрби операция ветераннары яши торган индивидуаль торак йортларны, күпфатирлы йортлардагы торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне тикшерү һәм яраклаштыру, ишегалды территорияләреннән аларның файдалана алуын тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

11.2. Махсус хәрби операция ветераннарына һәм аларның гаилә әгъзаларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында аларның ихтыяҗларын даими нигездә мониторинглауны гамәлгә ашырырга.

11.3. Махсус хәрби операция ветераннарына эшкә урнашуда һәм социаль яраклашуда ярдәм итәргә.

11.4. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ махсус хәрби операция ветераннарына һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль ипотека программасы буенча өстенлекле тәртиптә торак алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

12. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына махсус хәрби операция ветераннарына һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү буенча Татарстан Республикасында үткәрелә торган чаралар, шулай ук аларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында гражданнарга мәгълүмат бирү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

13. «Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасында күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында» 2025 елның 12 мартындагы 48-VII ДСП номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын контрольдән төшерергә.

14. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 531-VII ДС